Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр торак пунктында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елның 28 нче ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. 50% күләмендә ташлама билгеләнгән I группа инвалидлар, торып укучы студентлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләр, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән тыш, Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр авылында яшәү урыны буенча теркәлгән , балигъ булган һәр гражданга 2021 нче елда үзарасалымны 450 сум күләмендә кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Комсомол урамы буенча вак таш җәю;
- чишмәне төзекләндерү;
- Г.Тукай урамы буенча җәяүлеләр тротуарын урнаштыру;
- янгынга каршы җиһазлар сатып алу.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында,Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.Х.Салихҗанов